октябрь/ 2025

**МБМБУ «Яңа Кенәр балалар бакчасы»**

# Чишмә башы

*Ананың балага биргән иң зур бүләге-тел.*



## Алтын көз

Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде....
Үтте-китте матур жәйләр,
Көзләр килеп життеләр.
Ак каенның яфраклары
Саргаешып киптеләр.

## Көз турында сынамышлар:

а) Миләш күп булган елны көз озын һәм яңгырлы була.
б) Сентябрьдә алма, ә октябрьда кәбестә исе аңкый.
в) Агачтан яфрак сирәк коелса, кыш салкын бу-ла.
сакласын!

## *«Көз" уены*

Тәрбияче: И, балалар, күрегез,
Тышта әнә килә көз.
Балалар: Әйе, әйе, күрәбез,
Көз килгәнен беләбез.
Тәрбияче: Я әйтегез, сөйләгез,
Ничек килә икән көз?
Балалар: Кошлар оча көньякка,
Канат кагып еракка.
Аюлар өн казыды
Бик тирән итеп баз-ны.
Балыклар да тынды-лар,
Су төбенә чумдылар.
Агачлар ялангачлар,
Җилләрдә чайкалдылар.
Тик безгә куелле көз,
Без бакчага йөрибез.

# «Сөмбелә» килде.



*Октябрь аенда балалар бакчасы төркемнәрендә “Сөмбелә” бәйрәме булып үтте. Сөмбелә бәйрәме иген-кырлардан уңышлар җыелып беткәч уздырыла. Көзге муллык - уңыш - басулардан җыеп алынган иген, бакчалардан җыелган яшелчә, җиләк - җимеш ул. Ә аларның безнең өчен файдасы бик зур. Бу бәйрәм туган җиребезгә, туган телебезгә мәхәббәт, игенче хезмәтенә, икмәккә хөрмәт, халкыбызның милли йолаларына ихтирам тәрбияли, белемнәрне шигырьләр, җырлар, табышмаклар, мәкальләр аша ныгыта. Балаларда күңел күтәренкелеге булдыра. Безнең балалар да бәйрәмдә шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар. Кунакка килгән Сөмбелә балалар белән төрле уеннар уйнады, табышмаклар әйтеп, тапкырлыкларын сынады.* Мәктәпкә хәзерлек төркеменә кунакка “Ашыт” табигый заказнигы специалисты Абдрахманова Гөлнара Ильясовна белән Минэкологияның Төньяк

# Республика семинарында.




*Безнең педагогларыбыз даими рәвештә төрле семинарларда, форумнарда катнашып, чыгыш ясап, белемнәрен күтәреп, тәҗрибә уртаклашып, үз эш алымнарын да күрсәтеп торалар.*

*Кечкенәләр төркеме тәрбиячесе Самигуллина Гүзәл Муллахмәт кызы Арча шәһәренең 7 нче номерлы балалар бакчасында узган « Этно-мәдани регионалҗ компонентны исәпкә алып мәктәпкәчә яшьтәге балаларда рухи-әхлаки аңны формалаштыру буенча эшнең нәтиҗәле ысуллары» исемле республика семинарында катнашып, «Балалар бакчасында милли-төбәк компонентын тормышка ашыру юллары» темасы чыгыш ясады, республиканың башка районнарыннан килгән педагогларның эш алымнары белән дә танышты.*

# *Бакчабызда көзге күргәзмә.*

Көзге күргәзмәгә нинди генә эшләнмәләр куелмаган! Һәрберсе үзенчәлекле, кабатланмас. Монда яфраклардан ясалган аппликацияләр дә, табигый материаллардан эшләнгән уенчыклар да, хәтта чын мәгънәсендә сәнгать әсәрләрен хәтерләткән композицияләр дә бар.

Әти-әниләр дә читтә калмаган, үзләренең осталыкларын күрсәткәннәр. Аларның фантазиясе чиксез икәнлегенә тагын бер кат инанасың. Кемдер кабактан көлкеле йөз ясаган, икенче берәү көзге яфраклардан чәчәк бәйләме җыйган, ә өченчеләре исә көзге урман күренешен тасвирлаган. Һәр эшләнмәдә балаларның күңел җылысы, иҗади карашы чагыла.

Бу күргәзмә балалар өчен генә түгел, әти-әниләр өчен дә бик файдалы булды. Ул гаиләләрне берләштерә, бергә вакыт уздырырга, иҗат белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирә. Мондый чаралар балаларның фантазиясен, креатив фикерләвен үстерергә ярдәм итә, аларга табигатькә мәхәббәт тәрбияли.

"Көзге күргәзмә" балалар бакчасында матур традициягә әверелгән.



# *Балаларыбыз өчен көз турында табышмаклар*

Хәр көн диярлек Елап яшь коя. Килгән кошларны Көньякка куа. Бу кайсы вакыт? ( Көз) Күктәнкилде,җиргәкитте. (Яңгыр) Аяксыз-кулсыз дөп-дөп кое казый. (Тамчы)

Яз килсә – киенә, Көз килсә – чишенә. (Агач)

Язын дөньяга килә, Көзен саргаеп үлә. (Яфрак)

Аяксыз, кулсыз, капка ача. (Җил)

Агач бөгә – кулы юк, йөри торган юлы юк. Ачуланса – сызгыра, тузаннарны туздыра. (Җил) Аягы юк, кулы юк, үзе сүрәт төшерә. (Суык)

# *Балалар рәсем ясыйлар.*

Кече яшьтәге балалар рәсем ясарга, буярга бик яраталар. Бүяулар мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен бик мөһим. Рәсемнәрне буяганда балаларда кулларның вак моторикасы үсә, бу турыдан-туры баланың фикерләү сәләте үсеше белән бәйле.



· Телефон: 8(84366)91-1-32
422031, Республика Татарстан, Арский район, с.Новый Кинер, улица Пионерская, дом 10

*Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение «Новокинерский детский сад» Арского муниципального района Республики Татарстан функционирует с 30 декабря 2003 года.*

**График работы МБДОУ «Новокинерский детский сад":**

Понедельник - с 7.00 до 17.30

Вторник – с 7.00 до 17.30

Среда - с 7.00 до17.30

Четверг - с 7.00 до 17.30

Пятница - с 7.00 до17.30

[ адрес официального сайта ДОУ: https://edu.tatar.ru/arsk/n-kiner/dou ]